КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 декабрь г.Казань № 1301

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә граждан-нарга түләүсез медицина ярдәме күрсә-түнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 ел, 30 декабрь, 1239 нчы карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре програм-масына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 ел, 30 декабрь, 1239 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 июнь, 445 нче; 2021 ел, 26 июль, 656 нчы; 2021 ел, 1 декабрь, 11660 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа), Программаның III бүлегендәге 2 пунктына түбәндәге абзацларны өстәп, үзгәреш кертергә:

«полимераза чылбырлы реакциясе ысулы белән яңа коронавирус йогышлы авыруының булу-булмавына түбәндәге очракларда тикшерүләр үткәрү:

иминләштерелгән гражданнарда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) булуын бетерми торган симптомнар барлыкка килгәндә, этиологиясе ачык билгеле булмаган, салкын тиюдән булган кыскен авыру билгеләре булганда;

иминләштерелгән гражданнарда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) булганда, шул исәптән үткәрелә торган дәвалау нәтиҗәләрен бәяләү өчен;

экспресс-тест кулланып алынган яңа коронавирус йогышлы авыруын (COVID-19) барлыкка китерүчене ачыклау буенча тикшеренү уңай нәтиҗә биргәндә (граждан яки экспресс-тест ясауга вәкаләтле оешма тарафыннан әлеге тест медицина оешмасына тапшыру шарты белән).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин